**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** _28.10.2014_

г. Казань

**БОЕРЫК** ___774-п___

**Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалана алуны тәэмин итү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимияте органнарының эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалана алуны тәэмин итү турында”гы №919 карарын гамәлгә ашыру максатларында,

**БОЕРЫК БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының Татарстан Республикасының “Татарстан Республикасының рәсми порталы” дәүләт мәгълүмати системасы составындагы рәсми сайтында урнаштырылучы, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы эшчәнлеге турында мәгълүматның кушымта булып килүче Исемлеген расларга.

2. Хокукый тәэминат бүлегенә әлеге боерыкны теркәүгә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министр урынбасары М.Р. Бакаевка йөкләргә.

Министр А.Г. Сидоров

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигый ресурслар
министрлыгының
2014 елның “28”октябрендәге
№774-п боерыгына кушымта

**Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының Татарстан Республикасының “Татарстан Республикасының рәсми порталы” дәүләт мәгълүмати системасы составындагы рәсми сайтында урнаштырылучы, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы эшчәнлеге турында мәгълүмат**

**ИСЕМЛЕГЕ**

| № п/п | Мәгълүматның категориясе | Урнаштыру ешлыгы | Мәгълүматны урнаштыру өчен җаваплылар |
|---|---|---|---|
| **I. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы (алга таба - Министрлык) эшчәнлеге турында гомуми мәгълүмат** | | | |
| 1. | Министрлыкның тулы һәм кыскартылган аталышы, почта адресы, мәгълүматтан файдаланучыларга гарызнамәләрен җибәрү һәм соратып алына торган мәгълүматны алу өчен электрон почта адресы, белешмә хезмәтенең, матбугат хезмәтенең телефон номерлары һәм, булган очракта, ышаныч телефоны номеры | Актуаль торышта тәэмин ителә | Җыелма бүлек<br>Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге |
| 2. | Министрлыкның вәкаләтләре, аның структур бүленешләренең бурычлары һәм функцияләре турында мәгълүматлар, шулай ук Министрлыкның вәкаләтләрен билгели торган норматив-хокукый актлар исемлеге | Тиешле норматив хокукый һәм башка төрле актлар расланганнан соң яки аларга үзгәрешләр кертелгәннән соң 5 эш көне дәвамында.<br>Законнарның һәм башка төрле норматив-хокукый актларның исемлеге актуаль торышта тәэмин ителә | Хокукый тәэминат бүлеге<br>Җыелма бүлек |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3. | Министрлыкның үзәк аппаратының һәм территориаль идарәләренең структурасы | Структураны раслаганнан соң яисә үзгәрткәннән соң 5 эш көне дәвамында | Хокукый тәэминат бүлеге,<br>Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге,<br>Җыелма бүлек |
| 4. | Министрлыкның, аның структур бүлекчәләренең һәм территориаль идарәләренең җитәкчеләре турында мәгълүматлар, нигездә фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, шулай ук күрсәтелгән затларның ризалыгы белән алар турында башка төрле мәгълүматлар | Билгеләнгәннән соң 3 эш көне дәвамында.<br>Актуаль торышта тәэмин итеlә | Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге,<br>Матбугат хезмәте |
| 5. | Министрлыкның территориаль идарәләре исемлеге, аларның бурычлары һәм функцияләре турында мәгълүматлар, шулай ук күрсәтелгән органнарның һәм вәкиллекләрнең (вәкилләренең) почта адреслары, электрон почта (булган очракта) адреслары, белешмә хезмәте телефон номерлары | Территориаль идарә яки вәкиллекне оештыру турында хокукый акт имзаланганнан соң 5 эш көне дәвамында. Актуаль торышта тәэмин итеlә | Хокукый тәэминат бүлеге<br>Министрлыкның территориаль идарәләре |
| **II. Министрлыкның нормалар чыгару эшчәнлеге турында мәгълүмат** | | | |
| 6. | Министрлык тарафыннан чыгарылган актлар (карарлар, боерыклар, әмернамәләр, кагыйдәләр, инструкцияләр, кушымталар һәм башка актлар), аларга кертелгән үзгәрешләр, аларны көчен югалткан дип тану, шулай ук дәүләт теркәвенә алу турындагы мәгълүматларны да исәпкә алып | Тиешле документны имзалаганнан соң (раслаганнан соң) 5 эш көне дәвамында | Хокукый тәэминат бүлеге |
| 7. | Министрлыкның норматив-хокукый актларын гамәлдән чыккан дип тану турындагы эшләр буенча суд карарлары турында мәгълүматлар | Суд карары Министрлыкка ирешкән көннән алып 5 эш көне дәвамында | Хокукый тәэминат бүлеге |
| 8. | Федераль һәм республика законнары проектлары, Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актларының проектлары, Министрлык тарафыннан эшләнүче республика максатчан программалары һәм концепцияләре турында мәгълүматлар | Актуаль торышта тәэмин итеlә | Хокукый тәэминат бүлеге |
| 9. | Административ регламентлар һәм дәүләт хезмәтләре стандартлары | Дәүләт теркәвенә алганнан соң 5 эш көне дәвамында | Дәүләт хезмәтләренә ия булган бүлекләр<br>Җыелма бүлек |
| 10. | Министрлыкның, территориаль идарәләренең һәм аларның вазыйфаи затларының норматив-хокукый актларын һәм башка төрле карарларын, гамәлләрен (гамәл кылмауларын) суд һәм административ тәртибендә шикаять кылу | Актуаль торышта тәэмин итеlә | Хокукый тәэминат бүлеге |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **III. Министрлыкның агымдагы (компетенциясе кысаларында) эшчәнлеге турында мәгълүмат** | | | |
| 11. | Министрлык тарафыннан күрсәтелүче (башкарылучы) дәүләт хезмәтләре һәм аларны күрсәтү (башкару) тәртибе турында мәгълүматлар | Актуаль торышта тәэмин ителә | Дәүләт хезмәтләренә ия булган бүлекләр<br>Җыелма бүлек |
| 12. | Министрлык эшчәнлегенең планнары һәм күрсәткечләре | Планны яки күрсәткечне раслаганнан соң 5 эш көне дәвамында | Җыелма бүлек |
| 13. | Заказчысы яки башкаручысы Министрлык булган федераль максатчан һәм (яки) дәүләт программаларының исемлеге | Актуаль торышта тәэмин ителә | Әйләнә-тирә мохитне саклау икътисады бүлеге |
| 14. | Федераль максатчан һәм (яки) дәүләт программаларын гамәлгә ашыруның нәтиҗәләре, максатчан күрсәткечләрне үтәү, максатчан һәм (яки) дәүләт программаларын үтәү буенча тотылган финанс ресурсларының күләме турында, шулай ук программа чараларын гамәлгә ашыруны мониторинглау нәтиҗәләре турында төп мәгълүматлар | Квартал саен | Әйләнә-тирә мохитне саклау икътисады бүлеге<br>Инвестиция программаларын үтәү бүлеге |
| 15. | Министрлыкның эшчәнлеге турында мәгълүмати һәм аналитик материаллар (докладлар, хисаплар һәм мәгълүмати характердагы күзәтүләр) | Актуаль торышта тәэмин ителә | Матбугат хезмәте<br>Җыелма бүлек<br>Министрлыкның структур бүлекчәләре |
| 16. | Министрлыкның Татарстан Республикасының башка дәүләт хакимияте органнары, җәмәгать берләшмәләре, сәяси партияләр, профессиональ берлекләр һәм башка, шул исәптән халыкара оешмалар белән үзара бәйләнеше турында мәгълүмат | Актуаль торышта тәэмин ителә | Экологик мәгърифәт һәм җәмәгать оешмалары белән үзара бәйләнеш бүлеге |
| 17. | Министрлыкның Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләрен һәм халыкара хезмәттәшлек турындагы программаларын гамәлгә ашыруда катнашуы турында мәгълүмат | Актуаль торышта тәэмин ителә | Экологик мәгърифәт һәм җәмәгать оешмалары белән үзара бәйләнеш бүлеге |
| 18. | Министрлык җитәкчеләренең һәм рәсми делегацияләренең рәсми визитлары һәм хезмәт сәяхәтләре турында, шулай ук Министрлык, аның территориаль идарәләре тарафыннан оештырылучы рәсми чаралар (утырышлар, очрашулар, брифинглар, семинарлар, “түгәрәк өстәлләр” һәм башка чаралар) турында мәгълүматлар, нигездә булачак рәсми | Рәсми визитның (хезмәт сәяхәтенең, рәсми чараның) анонслары – күрсәтелгән чаралар башланыр алдыннан бер эш көне дәвамында.<br>Рәсми визит (хезмәт сәяхәте, | Матбугат хезмәте |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | визитларның һәм хезмәт сәяхәтләренең, рәсми чараларның анонслары һәм аларның нәтиҗәләре | рәсми чара) нәтиҗәләре – күрсәтелгән чаралар тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында | |
| 19. | Министрлыкның һәм аның территориаль идарәләре җитәкчеләренең һәм урынбасарларының рәсми чыгыш һәм игълан текстлары | Чыгыш ясаганнан соң бер эш көне дәвамында | Матбугат хезмәте |
| 20. | Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау һәм фаразланган һәм барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләрдә аларның иминлеген тәэмин итү буенча күрелгән чаралар, һәм халыкны алардан саклау юллары һәм ысуллары турында мәгълүмат | Актуаль торышта тәэмин ителә | Дәүләт экология күзәтчелеге инспекциясе<br>Режим, мобилизацион әзерлек, гражданлык оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр секторы |
| 21. | Компетенцияләре кысаларында Министрлык һәм аның территориаль идарәләре тарафыннан үткәрелгән тикшерүләрнең нәтиҗәләре турында, шулай ук Министрлыкта, аның территориаль идарәләрендә үткәрелгән тикшерүләрнең нәтиҗәләре турында мәгълүмат | Тикшерү актларын имзалаганнан соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча | Министрлыкның структур бүлекчәләре |
| 22. | Министрлык тарафыннан үткәрелә торган дәүләт ихтыяҗлары өчен товарларны китерүгә, эшләрне башкаруга һәм хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру турында мәгълүмат | Актуаль торышта тәэмин ителә | Дәүләт заказлары һәм конкурслы торглар бүлеге |
| 23. | Министрлыкның территориаль идарәләре эшчәнлеге турында мәгълүмат | Актуаль торышта тәэмин ителә | Министрлыкның территориаль идарәләре |
| 24. | Министрлыкның территориаль идарәләре тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт экология күзәтчелеге буенча атна саен хисаплар | Атна саен | Министрлыкның территориаль идарәләре |
| 25. | Министрлыкның территориаль идарәләренең атна саен эш планнары | Атна саен | Министрлыкның территориаль идарәләре |
| 26. | Министрлыкның территориаль идарәләре җитәкчеләренең мәгълүмати һәм аналитик материаллары (докладлар, хисаплар һәм мәгълүмати характердагы күзәтүләр) | Квартал саен | Министрлыкның территориаль идарәләре |
| 27. | Министрлыкның территориаль идарәләренең гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән эше турында мәгълүмат | Квартал саен | Министрлыкның территориаль идарәләре |
| **IV. Министрлыкның эшчәнлеге турында статистик мәгълүмат** | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 28. | Аларны җайга салу Министрлык вәкаләтләренә кертелгән икътисади, социаль һәм башка тереклек эшчәнлеге өлкәләрендәге үсеш торышын һәм динамикасын сыйфатлый торган статистик мәгълүматлар һәм күрсәткечләр | Квартал саен | Җыелма бүлек<br>Әйләнә-тирә мохитне саклау икътисады бүлеге |
| 29. | Министрлыкның һәм аның территориаль идарәләренең бүлеп бирелә торган бюджет акчаларыннан файдалануы турындагы мәгълүматлар | Квартал саен | Финанс контроле, исәпкә алу һәм хисап бирү бүлеге |
| 30. | Дәүләт ихтыяҗлары өчен заказларны урнаштыру барышы турында статистик мәгълүмат (торгларда катнашучыларның уртача саны, янга калдыру проценты) | Ай саен | Дәүләт заказлары һәм конкурслы торглар бүлеге |
| **V. Министрлык тарафыннан оештырылган координация һәм киңәшмә органнары турында мәгълүмат** | | | |
| 31. | Министрлык тарафыннан төзелгән координация һәм киңәшмә органнары исемлеге | Төзегәннән соң 5 эш көне дәвамында | Җыелма бүлек |
| 32. | Координация һәм киңәшмә органнарын оештыруны һәм аның эшчәнлегенең хокукый нигезенен җайга салучы норматив-хокукый һәм башка төрле актлар | Норматив-хокукый актларны имзалаганнан соң 5 эш көне дәвамында | Экологик мәгърифәт һәм җәмәгать оешмалары белән үзара бәйләнеш бүлеге<br>Экологик мониторинг бүлеге<br>Җыелма бүлек<br>Министрлыкның структур бүлекчәләре |
| 33. | Координация һәм киңәшмә органнарының составы (координация һәм киңәшмә органнары җитәкчеләренең һәм әгъзаларының фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, вазыйфалары) турында мәгълүматлар, шулай ук урнашу адресы, телефон (факс) номерлары, электрон почта адресы | Норматив-хокукый актларны имзалаганнан соң 5 эш көне дәвамында | Экологик мәгърифәт һәм җәмәгать оешмалары белән үзара бәйләнеш бүлеге<br>Экологик мониторинг бүлеге<br>Җыелма бүлек<br>Министрлыкның структур бүлекчәләре |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 34. | Координация һәм киңәшмә органнарының утырышлары турында мәгълүмат, нигездә утырышларның анонслары, координация һәм киңәшмә органнары утырышларының беркетмәләре | Утырышларның анонслары утыршка кадәр 3 эш көненнән дә соңга калмыйча. Утырышларның беркетмәләре беркетмәне имзалаганнан соң 5 эш көне дәвамында | Экологик мәгърифәт һәм җәмәгать оешмалары белән үзара бәйләнеш бүлеге<br>Экологик мониторинг бүлеге<br>Җыелма бүлек<br>Министрлыкның структур бүлекчәләре |
| **VI. Министрлыкның кадрлар белән тәэмин ителеше турында мәгълүмат** | | | |
| 35. | Гражданнарның Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә керү тәртибе | Актуаль торышта тәэмин ителә | Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге |
| 36. | Министрлыкта һәм аның территориаль идарәләрендә булган дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфалары турында мәгълүмат | Вакант вазыйфасын игълан итү көненнән 3 эш көне дәвамында | Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге |
| 37. | Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең Министрлыкта һәм аның территориаль идарәләрендәге вакант вазыйфаларын биләү буенча кандидатларга карата квалификация таләпләре | Раслаганнан соң 5 эш көне дәвамында | Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге |
| 38. | Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларын биләүгә карата конкурсларның шартлары һәм нәтиҗәләре | Конкурсның шартлары конкурсны үткәрер алдыннан 5 эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла. Нәтиҗәләре – конкурсны үткәргәннән соң 3 эш көне дәвамында | Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге |
| 39. | Министрлыкта һәм аның территориаль идарәләрендә вакант вазыйфаларны биләү мәсьәләсе буенча мәгълүматны алырга мөмкин булган телефон номерлары, электрон почта адресы | Актуаль торышта тәэмин ителә | Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге |
| 40. | Министрлыкта һәм аның территориаль идарәләрендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларын биләүгә карата конкурсларны оештыру һәм үткәрү буенча комиссияләрнең составлары | Комиссиянең составын раслаганнан соң 5 эш көне дәвамында | Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге<br>Җыелма бүлек |
| 41. | Министрлыкта һәм аның территориаль идарәләрендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакант | Тәртипне раслаганнан соң 5 эш көне дәвамында | Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | вазыйфаларын биләүгә карата конкурс нәтиҗәләрен шикаять кылу тәртибе | | |
| 42. | Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттә үз-үзен тотышына карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясенең карап тикшерүенә гаризалар тапшыру тәртибен дә кертеп, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттә үз-үзен тотышына карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиянең эш тәртибе | Тәртипне раслаганнан соң 5 эш көне дәвамында | Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге |
| 43. | Министрлыкта һәм аның территориаль идарәләрендә коррупциягә каршы көрәш буенча күрелә торган чаралар турында мәгълүмат | Актуаль торышта тәэмин ителә | Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге |
| **VII. Министрлыкның гражданнарның (физик затларның), оешмаларның (юридик затларның), җәмәгать оешмаларының, дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының мөрәҗәгатьләре белән эшләве турында мәгълүмат** | | | |
| 44. | Министрлыкта һәм аның территориаль идарәләрендә гражданнарның (физик затларның), оешмаларның (юридик затларның), җәмәгать оешмаларының, дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының мөрәҗәгатьләре белән эшләү мәсьәләләрен җайга сала торган норматив-хокукый һәм башка төрле актлар | Норматив-хокукый актны һәм башка төрле актны раслаганнан соң 5 эш көне дәвамында | Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге<br>Документларны башкаруны тикшереп тору бүлеге |
| 45. | Гражданнарның (физик затларның), оешмаларның (юридик затларның), җәмәгать оешмаларының, дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе | Актуаль торышта тәэмин ителә | Координацияләү һәм планлаштыру бүлеге |
| 46. | Гражданнарны (физик затларны), шул исәптән оешмаларның (юридик затларның), җәмәгать оешмаларының, дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының вәкилләрен кабул итү тәртибе һәм вакыты | Тәртипне раслаганнан соң 5 эш көне дәвамында | Координацияләү һәм планлаштыру бүлеге |
| 47. | Гражданнарны, шул исәптән оешмаларның, җәмәгать оешмаларының, дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының вәкилләрен кабул итүне оештыру, аларның хәбәрләрен карап тикшерүне тәэмин итү бурычлары | Билгеләгәннән соң 5 эш көне дәвамында | Координацияләү һәм планлаштыру бүлеге<br>Җыелма бүлек |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | вәкаләтләренә кертелгән Министрлыктагы һәм аның территориаль идарәсендәге структур бүлекчә җитәкчесенең яки башка төрле вазыйфаи затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, шулай ук белешмә характердагы мәгълүматны алырга мөмкин булган телефон номеры, электрон почта адресы | | |
| 48. | Гражданнарның, шул исәптән оешмаларның, җәмәгать оешмаларының, дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнары вәкилләренең мөрәҗәгатьләренә күзәтү, шулай ук әлеге мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре турында гомумиләштерелгән мәгълүмат | Квартал саен | Министрлыкның структур бүлекчәләре |
| **VIII. Министрлык карамагындагы дәүләт мәгълүмати системалары турында мәгълүматлар** | | | |
| 49. | Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимияте органы карамагындагы дәүләт мәгълүмати системаларының, мәгълүматлар банкларының, реестрларының, регистрларының исемлеге | Актуаль торышта тәэмин ителә | Мәгълүмати системаларны үстерү һәм мәгълүматлаштыру бүлеге |
| 50. | Министрлык карамагында булган дәүләт мәгълүмати системаларыннан кызыксынган затлар тарафыннан файдалана алуның шартларын һәм тәртибен тасвирлау, шул исәптән мәгълүмати системалардан файдалана алуның яки мәгълүмати системалардан белешмәләр алуның түләүле булуы турында мәгълүмат | Раслаганнан соң 5 эш көне дәвамында | Мәгълүмати системаларны үстерү һәм мәгълүматлаштыру бүлеге |
| 51. | Дәүләт мәгълүмати системаларын булдыру, алып бару тәртибен, һәм шулай ук Министрлык карамагындагы дәүләт мәгълүмати системаларында булган мәгълүматтан кызыксынган затларның файдалана алу тәртибен җайга сала торган норматив хокукый һәм башка төрле актлар | Норматив-хокукый яки башка актны имзалаганнан соң 5 эш көне дәвамында | Мәгълүмати системаларны үстерү һәм мәгълүматлаштыру бүлеге |
| 52. | Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә Интернет челтәрендә урнаштырылырга тиешле Министрлык эшчәнлеге турында башка төрле мәгълүмат | Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән башка сроклар | Министрлыкның структур бүлекчәләре |